ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

***Постановление*** ***Карар***

**2022 елның 15 июле** **Чистай шәһәре** **№ 466**

Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ
табиб – белгечләргә торак бинаны
файдалануга алу (арендалау) өчен түләү
чыгымнарын компенсацияләр бирү
тәртибен раслау турында

Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының «2022-2024 елларга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында медицина кадрларын беркетү һәм аларны торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын раслау турында» 2022 елның 29 гыйнварындагы 433 номерлы карарын тормышка ашыру максатларында Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ табиб – белгечләргә торак бинаны файдалануга алу (арендалау) өчен түләү чыгымнарын компенсацияләр бирү тәртибен кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (http://chistopol.tatar.ru/) урнаштырырга.
3. Карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Г.Ю. Задворновага йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов

Чистай муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 елның 15 июлендәге
466 номерлы карарына
кушымта

ТОРАК ШАРТЛАРЫН ЯХШЫРТУГА МОХТАҖ ТАБИБ – БЕЛГЕЧЛӘРГӘ ТОРАК БИНАНЫ ФАЙДАЛАНУГА АЛУ (АРЕНДАЛАУ) ӨЧЕН ТҮЛӘҮ ЧЫГЫМНАРЫН КОМПЕНСАЦИЯЛӘР БИРҮ ТӘРТИБЕ

## 1. Гомуми нигезләмәләр.

1.1. Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының «2022-2024 елларга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында медицина кадрларын беркетү һәм аларны торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын раслау турында» 2022 елның 29 июнендәге 433 номерлы карары нигезендә табиб-белгечләргә торак бинаны файдалануга алу (арендалау/субарендалау) өчен түләү чыгымнарын компенсацияләүнең әлеге тәртибе бердәм тәртипне билгеләү һәм җирле бюджет акчаларының торак бинаны файдалануга алу (арендалау/субарендалау) өчен түләү чыгымнарын җайга салуны тәэмин итү максатларында эшләнгән һәм торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ (алга таба текст буенча - Программа) табиб – белгечләргә (алга таба текст буенча – табиб-белгеч) ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелгән.

1.2. Торак бинаны файдалануга алу (арендалау) бәясе өчен түләү чыгымнарын каплау хокукына программада күрсәтелгән таләпләргә туры килә торган табиблар - белгечләр ия, ә атап әйткәндә:

- «Чистай үзәк район хастаханәсе» ДАССУ белән хезмәт мөнәсәбәтләрендә торучылар;
- 5 календарь ел элек Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлмәгән (ЧМР территориясендә башка Республикалардан җәлеп ителгән табиблар - белгечләрне теркәгән очракта искәрмә);
- табиб – белгечнең һәм аның гаилә әгъзаларының Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы территориясендә урнашкан торак урыннар милкендә булмавы.

## 2. Табиб-белгечләргә торак бинаны файдалануга алу (арендалау) белән бәйле чыгымнарны компенсацияләр бирү тәртибе

2.1 Компенсацияләү билгеләнгән тәртиптә Чистай муниципаль районында торак биналары бирүгә мохтаҗлар буларак исәпкә алынган табиб-белгечләргә турыдан-туры эш урыны буенча башкарыла.

2.2. Компенсация түләү турындагы мәсьәләне карау өчен табиб - белгеч шәхсән «Чистай үзәк район хастаханәсе» ДАССУ баш табибы исеменә гариза белән мөрәҗәгать итә, Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты каршында торак бинаны файдалануга алу (арендалау/субарендалау) өчен түләү чыгымнарын компенсацияләү (алга таба - компенсацияләү) турында сорап мөрәҗәгать итә. Гаризага табиб - белгеч Программада билгеләнгән документларны теркәп куя, ә атап әйткәндә:

- торак бинаны файдалануга алу (арендалау) шартнамәсе (Башкарма комитет аша субарендага торак бина бирү очракларыннан тыш);
- программада катнашучының һәм аның гаилә әгъзаларының шәхесен таныклаучы документларның күчермәләре (паспорт яки аны алмаштыручы башка документ);
- «Чистай үзәк район хастаханәсе» ДАССУ белән хезмәт мөнәсәбәтләре булуны раслый торган документларның тиешле таныкланган күчермәләре (хезмәт кенәгәсендә тиешле язу шартнамәсе);
- программада катнашучының гаилә мөнәсәбәтләрен раслаучы документларның күчермәләре (никахлашу турында таныклык, никахны өзү турында таныклык, бала (балалар) туу турында таныклык);
- йорт китабыннан яки финанс – шәхси счеттан өземтә, фатир карточкасы;
- программада катнашучы һәм аның гаилә әгъзалары билгән торак бинадан файдалану хокукын раслый торган документлар.

2.3 «Чистай үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетына табиб - белгеч тарафыннан бирелгән барлык документларны да кертеп, Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты белән табиб арасында Килешү төзү турында үтенеч белән мөрәҗәгать итә.

2.4 «Чистай үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибыннан алынган үтенечнамәне, кушымта итеп бирелгән документлар белән, Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты 1 ай дәвамында карый. Мөрәҗәгатьне карау нәтиҗәләре буенча Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты табиб - белгеч белән торак бинаны файдалануга алу (арендалау/субарендалау) өчен түләү чыгымнарын компенсацияләү турында Килешү төзи, 1 нче кушымта нигезендә 1 календарь елына форма буенча. Бирелгән документларның Тәртипнең 1.2 пунктына туры килмәгән очракта, килешү төзүдән баш тарту турында карар кабул ителә, бу хакта «Чистай үзәк район хастаханәсе» ДАССУга язмача хәбәр ителә.

2.5 Табиб – белгеч, киләсе айдан башлап, Килешү төзелгән көннән алып 15 числога кадәр, Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлегенә үзе һәм аның гаилә әгъзалары билгән торак бинаны файдалануга алу (арендалау/субарендалау) өчен түләүне раслый торган документлар тапшыра:

2.6 Торак бинаны файдалануга алу (арендалау/субарендалау) өчен компенсация түләү өчен табиб-белгеч бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлегенә түбәндәге документларны тапшыра:
- акчаларны күчерү өчен счетлар ачу турында банк учреждениесе белән шартнамә;
- акчаларны ачык счетка күчерү турында гариза.

2.7 «Чистай үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибы ай саен, айның 3 числосына кадәр, Чистай муниципаль районы Башкарма комитетына «Чистай үзәк район хастаханәсе» ДАССУ белән хезмәт мөнәсәбәтләрендә торучы табиб – белгечләр турында мәгълүмат бирә, аларга карата Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты адресына юлламалар әзерләнгән һәм компенсация түләү турында Килешүләр төзелгән.

2.8 Узган ай ахыры торышы буенча «Чистай үзәк район хастаханәсе» ДАССУ белән хезмәт мөнәсәбәтләрендә торган табиб-белгечләр турында мәгълүмат «Чистай үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе тарафыннан расланган очракта Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге табиб-белгеч раслаган документларны тапшырганнан соң 15 эш көненнән дә артмаган вакыт эчендә табиб – белгечкә

компенсация түләүне банкта ачылган табиб-белгечнең исәп-хисап счетына акча күчерү юлы белән тәэмин итә.

### 3. Табиб-белгечләргә торак бинаны файдалануга алу (арендалау/субарендалау) белән бәйле чыгымнарның компенсация күләмен исәпләү тәртибе.

3.1 Табиб-белгечләргә компенсация түләү күләмен исәпләү Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге тарафыннан 2 нче кушымта нигезендә башкарыла.

3.2 Компенсация күләме торак бинаны файдалануга алу (арендалау/субарендалау) шартнамәсе белән билгеләнә, әмма «2022-2024 елларга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында медицина кадрларын беркетү һәм аларны торак белән тәэмин итү» расланган муниципаль программасында билгеләнгән 4000 сум күләмендәге максималь әһәмияттән артмаска тиеш.

### 4. Торак бинаны файдалануга алу (арендалау/субарендалау) белән бәйле чыгымнарның табиб-белгечләренә компенсация күләмен үзгәртү һәм түләүне туктату тәртибе.

4.1 Белгечләргә компенсация күләме, табиб-белгечне тәэмин итү өчен кирәкле арендага бирелә торган торак урын мәйданы үзгәргән очракта, төзәтмәләр кертелергә мөмкин, әмма 4000 сум күләмендә максималь әһәмияттән артмаска тиеш.

4.2 Компенсация түләве түбәндәге очракларда туктатыла:

- исәптән төшерү турында гариза бирү;
- «Чистай үзәк район хастаханәсе» ДАССУ белән хезмәт мөнәсәбәтләрен туктату;
- дәүләт хакимияте органыннан яисә җирле үзидарә органыннан торак урын сатып алуга яисә төзүгә бюджет акчаларын билгеләнгән тәртиптә алу;
- торак бинаны файдалануга алу (арендалау/субарендалау) шартнамәсенең гамәлдә булу вакытын тәгәлләү;
- башка муниципаль берәмлеккә чыгу.

Чистай муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 елның 15 июлендәге
466 номерлы карарына
1 нче кушымта

**ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҺӘМ ТАБИБ-БЕЛГЕЧ АРАСЫНДАГЫ "2022-2024 ЕЛЛАРГА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНДА МЕДИЦИНА КАДРЛАРЫН БЕРКЕТҮ ҺӘМ АЛАРНЫ ТОРАК БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ" ПРОГРАММАСЫН ГАМӘЛГӘ АШЫРУ КЫСАЛАРЫНДА КОМПЕНСАЦИЯ ТҮЛӘҮ ТУРЫНДА КИЛЕШҮ ___**

Чистай шәһәре «____» __________20__ ел

Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты (алга таба - Башкарма комитет) Устав нигезендә эш итүче Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе Хәсәнов Эдуард Рөстәм улы йөзеннән, _________________ (табиб-белгечнең фамилиясе, исеме, атасының исеме), Яклар дип аталучы, түбәндәгеләр турында әлеге Килешүне төзеделәр:

## 1. КИЛЕШҮ ПРЕДМЕТЫ

1.1. Әлеге Килешү Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районындагы торак бинаны файдалануга алу (арендалау/субарендалау) буенча компенсация рәвешендә табиб-белгечкә җирле бюджеттан акчалар түләү тәртибен һәм формасын билгели.

## 2. ЯКЛАРНЫҢ БУРЫЧЛАРЫ

2.1. Башкарма комитет табиб-белгечкә торак бинаны файдалануга алу (арендалау/субарендалау) чыгымнарын ай саен, табиб-белгеч тарафыннан бирелгән документлар нигезендә, 4000 сумнан да артык булмаган сумманы компенсацияләргә тиеш була.

2.2. Компенсация күләме торак урын өчен түләү күләмен арттыруга бәйле рәвештә үзгәрергә мөмкин.

2.3. Әлеге килешүнең 1 пунктында күрсәтелгән торак бинаны файдалануга алу (арендалау/субарендалау) буенча чыгымнарны компенсацияләү һәр айның _____ числосыннан да соңга калмыйча башкарыла.

2.4. Табиб-белгеч ай саен Башкарма комитетның бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлегенә «Чистай үзәк район хастаханәсе» ДАССУ белән хезмәт мөнәсәбәтләре булу турында белешмәләр тапшырырга тиеш.

2.5. Табиб-белгеч банк учреждениесендә үз исеменә счет ача, анда компенсация түләүләре керәчәк.

2.6. Компенсация түләүләре табиб-белгеч торак бинаны милеккә алган очракта туктатыла.

2.7. Торак бинаны файдалануга алу шартнамәсе әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булып тора.

## 3. БАШКА ШАРТЛАР

3.1. Әлеге Килешү яклар тарафыннан имзаланган вакыттан үз көченә керә һәм бер елга төзелә.

3.2. Якларның берсе берьяклы тәртиптә Килешүне өзәргә ниятләгән очракта, бу хакта башка Якка кимендә 30 календарь көн эчендә хәбәр итәргә кирәк.

3.3. Әлеге Килешү өч нөсхәдә төзелгән, аларның һәрберсе бертөрле юридик көчкә ия.

3.4. Кабул ителгән йөкләмәләрне үтәгәндә, Яклар гамәлдәге законнар нигезләмәләренә таяна һәм билгеләнгән компетенция чикләрендә эш итә.

3.5. Әлеге килешүгә үзгәрешләр яисә өстәмәләр кертү кирәк булган очракта, Яклар тарафыннан әлеге килешүнең аерылгысыз өлешенә әверелә торган тиешле өстәмә килешүләр имзалана.

3.6 Әлеге килешү кысаларында барлыкка килә торган барлык бәхәсләр һәм каршылыклар сөйләшүләр юлы белән - судка кадәр тәртиптә җайга салынырга тиеш.

## 4.ЮРИДИК АДРЕСЛАР ҺӘМ ЯКЛАРНЫҢ РЕКВИЗИТЛАРЫ

| | |
|---|---|
| Муниципаль берәмлек<br>Башкарма комитеты<br>Юридик адрес:<br>422980, Чистай шәһәре,<br>Бебель урамы, 129 нчы йорт<br>____________Хәсәнов Э.Р. | Табиб белгечнең Ф.И.О.<br>Яшәү урыны буенча адрес:<br><br><br><br>_________________ Ф.И.О. |

Чистай муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 елның 15 июлендәге
466 номерлы карарына
2 нче кушымта

ТОРАК БИНАЛАРНЫ ФАЙДАЛАНУГА АЛУ (АРЕНДАЛАУ/СУБАРЕНДАЛАУ) БЕЛӘН БӘЙЛЕ ТАБИБ-БЕЛГЕЧКӘ КОМПЕНСАЦИЯ КҮЛӘМЕН ИСӘПЛӘҮ ТӘРТИБЕ

1. Торак бинаны файдалануга алуга (арендалауга/субарендалауга) түләүне компенсацияләү өчен бүлеп бирелгән җирле бюджет акчаларыннан файдалануны контрольдә тотуны көчәйтү максатларында түләү тәртибе әлеге Тәртипнең 2 бүлеге белән җайга салына.

2. Компенсация күләме файдалануга алу (арендалау/субарендалау) шартнамәсендә билгеләнгән һәм торак бинаны файдалануга алу (арендалау/субарендалау) өчен табиб-белгеч тарафыннан документлар белән расланган чыгымнардан һәм әлеге Тәртипнең 3.3 пункты белән билгеләнгән максималь ихтимал компенсациянең күләменнән артмаска тиеш.

3. Компенсациянең максималь күләме табиб-белгечне һәм торак бинаны файдалануга алуның (арендалау/субарендалауның) иң чик бәясен торак урынның 1 кв. метрын тәэмин итү өчен кирәкле торак урын мәйданыннан чыгып түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$C_{макс} = C_o \times S_{пол,}$ монда

$C_{макс}$ - максималь мөмкин булган компенсация күләме (4000 сум);
$C_o$ – торак урын мәйданының 1 кв. метрын файдалануга алуның иң чик бәясе;
$S_{пол}$ – табиб-белгечне тәэмин итү өчен кирәкле торак бина мәйданы.

Раслыйм
Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
________________________ Э.Р. Хәсәнов

Табиб-белгечләргә торак бинаны файдалануга алу (арендалау) өчен түләү чыгымнарын компенсацияләү турында белешмәләр
«___» ________ 20__ елдан «___» _________ 20__ елына кадәрге чорда

| Табиб-белгечнең фамилиясе, исеме, атасының исеме Табиб-белгечнең гаризаларны исәпкә алу кенәгәсендә компенсация түләү турындагы гаризасын теркәү датасы | Торак комиссиясе карары | | Табиб-белгеч һәм аның гаилә әгъзалары милкендә яки урнашу урыны буенча социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны мәйданы (кв. м) Урнашу урыны | Шартнамәнең гамәлдә булу вакыты | Яшәү урыны адресы | Торак бинаны файдалануга алу (арендалау) шартнамәсе нигезендә торак бинада яшәүче гаилә әгъзаларының (табиб-белгечне дә кертеп) саны | Табиб-белгечне тәэмин итү өчен кирәкле торак бина мәйданы | Россия Хезмәт министрлыгы боерыгы нигезендә 1 кв. м. торакны файдалануга алу (арендалау) бәясе (сум) | Торак бинаны файдалануга алу (арендалау) өчен түләү күләме | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую турында (датасы, беркетмә номеры, исәпкә кую нигезе). | Компенсация түләү турында (датасы, беркетмә номеры, компенсация түли башлау датасы). | | | | | | | Торак бинаны файдалануга алу (арендалау) шартнамәсе нигезендә бер ай эчендә | Компенсация түләү нормасын исәпләп чыгару буенча бер ай эчендә һәм Тәртипнең 3.1 пункты | Исәп-хисап чорында барлыгы |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | буенча торак бинаны файдаланунуга алу (кв.м) | | | | | | | нигезендә | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
| | | | | | | | | | | | |

Бухгалтерлык исәбе
һәм хисаплылык бүлеге башлыгы

_________________ Г.Ф. Шаһиева

Торак сәясәте бүлеге башлыгы

____________________ Х.Р. Нуруллина